Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советының егерме беренче утырышы

Кощаково авыл җирлеге Советы карары

14 декабрь, 2022 ел № 68

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советының «Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында» 2019 елның 23 сентябрендәге 53 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 339-ФЗ номерлы Федераль законга таянып Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советының «Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында» 2019 елның 23 сентябрендәге 53 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 13 пунктны өстәргә:

«13) нотариаль расланган килешүләрнең эчтәлеген чагылдыра торган документларның дубликатларын бирергә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар 2023 елның 11 гыйнварыннан үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова